КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 592

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Участок табиблары-терапевтларына, участок табиблары-педиатрларына, гомуми практика табибларына (гаилә табибларына), участок табиблары-терапевтларының, участок табиблары-педиатрларының шәфкать туташларына һәм гомуми практика табибларының (гаилә табибларының) шәфкать туташларына стимуллаштыру характерындагы акчалата түләүләр турында» 2009 ел, 16 март, 148 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2009 ел, 24 декабрь, 880 нче карарындагы 5 пунктының егерме икенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 елга, 2012 һәм 2013 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 27 декабрь, 1122 нче карарындагы 5 пунктының егерме беренче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2011 ел, 5 декабрь, 994 нче карарындагы 5 пунктының унсигезенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кан хезмәтен үстерү чараларын тормышка ашыруга лицензияле программа тәэминаты белән компьютер һәм челтәр җайланмаларын сатып алуларны финанслар белән тәэмин итү өчен

федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану турында» 2013 ел, 20 август, 581 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруга бәйле булган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 октябрь, 730 нчы карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин